ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын һәм техник белгечләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында аккредитацияләү кагыйдәләре турында

Массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренең Татарстан Республикасы Дәүләт Советы эшен яктыртудагы профессиональ эшчәнлеге өчен кирәкле шартлар тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

1. Массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын һәм техник белгечләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. “Журналистларны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында аккредитацияләү нигезләмәсе һәм тәртибе турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумының 2005 елның 16 ноябрендәге 1728-III ДС номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Р.А. Ратниковага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2016 елның 26 октябре
№ 1426-V ГС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2016 елның 26 октябрендәге
1426-V ДС номерлы
карарына кушымта

# Массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын һәм техник белгечләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын һәм техник белгечләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында аккредитацияләү (алга таба шулай ук – аккредитацияләү) “Массакүләм мәгълүмат чаралары турында” Россия Федерациясе Законы, “Дәүләт массакүләм мәгълүмат чараларында дәүләт хакимияте органнары эшчәнлеген яктырту тәртибе турында” Федераль закон, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Кагыйдәләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Аккредитацияләү Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Матбугат хезмәте тарафыннан (алга таба – Матбугат хезмәте) түбәндәге максатларда башкарыла:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы (алга таба – Дәүләт Советы) эшчәнлеге турында объектив мәгълүматны киң, тиз һәм ирекле тарату;

федераль законнарда каралган тәртиптә аккредитацияләнгән журналистларның эшен оештыру.

## II. Массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын һәм техник белгечләрен Дәүләт Советы каршында аккредитацияләү төрләре

3. Аккредитацияләү түбәндәге сыйфатларда гамәлгә ашырыла:

парламент хәбәрчеләре;

махсус хәбәрчеләр;

электрон матбугат.

4. Парламент хәбәрчеләре сыйфатында аккредитацияләү Дәүләт Советы бинасында даими эшләүче һәм Дәүләт Советы эшен яктыртучы массакүләм мәгълүмат чаралары (алга таба – ММЧ) журналистлары өчен башкарыла.

5. Махсус хәбәрчеләр сыйфатында аккредитацияләү редакцияләрнең Дәүләт Советы эшен яктырту буенча конкрет йөкләмәләрен үтәүче ММЧ журналистлары өчен гамәлгә ашырыла.

6. Электрон матбугат сыйфатында аккредитацияләү телевизион аппаратура һәм тавыш аппаратурасы эшен тәэмин итүче һәм редакцияләрнең Дәүләт Советы эшен яктырту буенча конкрет йөкләмәләрен үтәүче ММЧ редакцияләренең техник белгечләре өчен башкарыла.

7. Аккредитацияләнгән затлар бер календарь елга (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) "Парламент хәбәрчесе", "Махсус хәбәрче" һәм "Электрон матбугат" дип язылган аккредитация карточкалары алалар.

Аккредитация карточкасында түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла: аккредитацияләнгән затның фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, фотосурәте, ММЧ исеме, аккредитация төре.

8. Дәүләт Советы үткәрә торган аерым чараларны киңрәк яктырту зарурлыгы булганда журналистлар һәм техник белгечләр өчен ММЧ редакциясенең язмача заявкасы нигезендә, Дәүләт Советы тарафыннан аккредитация карточкасы бирелмичә генә, өстәмә бер тапкыр аккредитацияләү башкарылырга мөмкин.

## III. Аккредитацияләү тәртибе

9. Матбугат хезмәте агымдагы аккредитациянең гамәлдә булу чоры тәмамланырга 45 көннән дә соңга калмыйча ММЧ редакцияләренә чираттагы аккредитацияләү кагыйдәләре һәм сроклары турында хәбәр итә һәм 20 көннән дә соңга калмыйча аккредитацияләүгә заявкалар кабул итүне тәмамлый.

10. Аккредитацияләүгә заявка ММЧ редакциясе тарафыннан язма рәвештә рәсми бланкта редакция җитәкчесе имзасы белән Дәүләт Советы Секретаре исеменә бирелә, аңа ММЧ дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе, эшләүгә лицензия күчермәсе (электрон ММЧ өчен) кушыла, заявка мөһер белән таныклана (мөһер булганда).

11. Әлеге Кагыйдәләрне һәм аккредитация өчен билгеләнгән срокларны бозып рәсмиләштерелгән аккредитацияләүгә заявкалар карауга кабул ителми.

12. Дәүләт Советы, эш урыннарын биргән һәм профессиональ эшчәнлекләре өчен кирәкле шартлар тудырган килеш, йөзләп журналистны һәм техник белгечне аккредитацияләү өчен техник мөмкинлеккә ия.

13. Дәүләт Советы үз эшчәнлекләре буенча реклама ясаучы, махсуслаштырылган басмалар булган йә парламентның закон чыгару эшчәнлеген яктырту белән шөгыльләнмәүче ММЧ редакцияләре журналистларына аккредитация бирүне кире кагарга хокуклы.

14. Матбугат хезмәте ММЧ редакцияләренең заявкалары нигезендә журналистларны һәм техник белгечләрне аккредитацияләү турында карар

кабул итә һәм аккредитацияләү хакындагы күрсәтмә проектын Дәүләт Советы Секретарена тәкъдим итә. ММЧ журналистларын һәм техник белгечләрен Татарстан Республикасы Дәүләт Советы каршында аккредитацияләү турындагы күрсәтмә, Дәүләт Советы Секретаре тарафыннан имза салынганнан соң, Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштырыла.

15. «Парламент хәбәрчесе», «Махсус хәбәрче» һәм «Электрон матбугат» дип язылган аккредитация карточкаларын аккредитацияләнүче затлар Матбугат хезмәтендә шәхсән алалар.

16. Журналист яисә техник белгеч яки ММЧ редакциясе тарафыннан әлеге Кагыйдәләр таләпләре бозылса йә чынбарлыкка туры килми торган, Дәүләт Советының дәрәҗәсен, шулай ук Дәүләт Советы депутатларының дәрәҗәсен һәм абруен төшерә торган белешмәләр таратылса һәм бу закон көченә кергән суд карары белән расланган булса, «Массакүләм матбугат чаралары турында» Россия Федерациясе Законы нигезендә журналист яисә техник белгеч аккредитацияләнүдән мәхрүм ителергә мөмкин.

17. Матбугат хезмәте үз эшчәнлеген туктаткан яисә туктатып торган ММЧ редакцияләре журналистларының һәм техник белгечләренең аккредитацияләрен юкка чыгара.

18. Журналист яисә техник белгеч эштән азат ителгән, ММЧ редакциясе карары буенча аларның аккредитацияләре кире алынган очракта, ММЧ редакциясе җитәкчесе бу хакта кичекмәстән Матбугат хезмәтенә хәбәр итә, шуннан соң әлеге журналистның яисә техник белгечнең Дәүләт Советы каршындагы аккредитациясе туктатыла.

19. Аккредитация карточкалары югалган, урланган яисә бозылган очракта, ММЧ редакциясе яисә аларны югалткан затлар күрсәтелгән хәлләр турында язма рәвештә кичекмәстән Матбугат хезмәтенә хәбәр итәргә тиеш. Әлеге затларның аккредитациясе юкка чыгарыла. Күрсәтелгән затларның яңа аккредитация алулары турындагы мәсьәлә Матбугат хезмәте тарафыннан әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә карала.

## IV. ММЧ редакцияләренең аккредитацияләнгән журналистларының һәм техник белгечләренең хокуклары һәм бурычлары

20. Аккредитацияләнгән журналистлар һәм техник белгечләр түбәндәгеләргә хокуклы:

1) Дәүләт Советы бинасында урнашкан махсус бүлеп бирелгән урыннарда, шулай ук Дәүләт Советы чаралары үткәрелә торган башка урыннарда Дәүләт Советында ачык чаралар үткәрелгән вакытта эшләргә;

2) Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе чикләрендә редакцияләр белән элемтәгә чыгу һәм оператив хәбәрләр тапшыру өчен шәһәр телефон элемтәсенең абонент номерларыннан, махсус бүлеп бирелгән урында

билгеләнгән мәгълүмат һәм телекоммуникация технологияләреннән һәм оештыру техникасыннан файдаланырга;

3) Матбугат хезмәте тарафыннан махсус оештырыла торган брифингларда, очрашуларда һәм матбугат конференцияләрендә һәм Дәүләт Советы чараларында Дәүләт Советы эшчәнлеге турында мәгълүмат алу өчен катнашырга.

21. Аккредитация алу өчен заявка бирү ММЧ журналистларының һәм техник белгечләренең түбәндәге махсус таләпләрнең үтәлергә тиешлеге белән килешүен раслый:

1) үз һөнәри эшчәнлеген башкарганда Дәүләт Советы депутатларының һәм Дәүләт Советы Аппаратындагы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хокукларын, законлы мәнфәгатьләрен, дәрәҗәсен һәм абруен ихтирам итү;

2) журналистларның һөнәри әдәп нормаларын үтәү;

3) укучыларга, телевизор караучыларга һәм радио тыңлаучыларга Дәүләт Советы эше турында күпкырлы һәм объектив мәгълүмат җиткерү;

4) үз һөнәри мөмкинлекләреннән мәгълүматны яшереп калу яисә иҗтимагый әһәмиятле белешмәләрне дөрес күрсәтмәү, дөрес хәбәрләр дип ялган мәгълүмат тарату, чит зат яисә массакүләм мәгълүмат чарасы булып тормаган оешма файдасына мәгълүмат җыю өчен файдаланмау;

5) үз хокукларыннан Дәүләт Советы депутатларын һәм Дәүләт Советы Аппаратындагы дәүләт граждан хезмәткәрләрен җенесенә, яшенә, нинди расадан һәм милләттән булуына, теленә, дингә мөнәсәбәтенә, һөнәренә, яшәү һәм эшләү урынына, шулай ук сәяси карашларына бәйле рәвештә кимсетү өчен файдаланмау;

6) Дәүләт Советы бинасында җәмәгать тәртибен һәм үз-үзеңне тоту нормаларын бозмау;

7) Дәүләт Советы бинасына кергәндә (бинадан чыкканда), шулай ук һөнәри эшчәнлекне гамәлгә ашырганда “Парламент хәбәрчесе”, “Махсус хәбәрче”, “Электрон матбугат” аккредитация карточкасын, шәхесне тәгаенли торган документ (бер тапкыр бирелә торган аккредитация алган журналистлар һәм техник белгечләр өчен) күрсәтү;

8) Дәүләт Советы җитәкчелегеннән интервью алу һәм очрашулар оештыру өчен Матбугат хезмәтенә заявкалар бирү. Дәүләт Советы депутатлары белән очрашулар оештырганда Дәүләт Советы Аппараты хезмәткәрләре белән хезмәттәшлек итү;

9) Дәүләт Советындагы чараларга килгәндә киемнең эшлекле стильдә булуы.